Сираева, Л. Чаллыда - Әдәбият көне / Л. Сираева // Мәйдан. – 2025. – № 12 (289). – Б. 149-150.



# Чаллыда – Әдәбият көне

2025 елның 21 ноябрендә Яр Чаллыда Әдәбият көне узды. Шәһәрдә ел саен үткәрелә торган бу чара Татарстан Язучылар берлегенең Яр Чаллы оешмасы төзелүгә 45 ел тулу уңае белән һәм күренекле шагыйрь Данис Хәйруллинның 80 яшьлек юбилее уңаеннан Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты, Татарстан Язучылар берлеге, Бөтендөнья татар конгрессы, Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы Татар дәүләт драма театры тарафыннан оештырылды.



Тантанага Казаннан, Татарстан төбәкләреннән мәртәбәле әдипләр килде, аларга Яр Чаллыда яшәүче каләмдәшләре кушылды. Шәһәр җитмештән артык каләм остасын, егермегә якын конгресс активын җыйды. Әдәбият көне язучыларның эшлекле сөйләшүе белән башланып китте. Килгән кунакларга шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Винер Харисов Яр Чаллыда мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә милли тәрбия һәм гыйлем бирүнең торышы турында сөйләде. Татарстан Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин Чаллы Язучылар оешмасы төзелү тарихы хакында чыгыш ясады.







Әдәбият бәйрәме шәһәрнең егерме мәктәбендә укучылар белән очрашулар буларак дәвам итте.

Данис Хәйруллинның юбилеена багышланган тантана Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында үтте. Юбилярны шәһәр Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Винер Харисов, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, ТР Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ирек Шәрипов, «Чаллы икмәге» АҖ генераль директоры Рафаэль Юнысов котлады. Винер Харисов юбилярга шәһәр хакиме исеменнән Рәхмәт хаты, Яр Чаллы Язучылар оешмасының 45 еллыгы уңае белән Бүлеккә шәһәр хакименең Мактау грамотасын тапшырды.

Данис Хәйруллин иҗатына багышланган шигъри-музыкаль тантанада шагыйрьнең үз шигырьләренә язылган җырлар да яңгырады. Сәхнәне, театр артистлары белән берлектә, Чаллының 2 нче, 29 нчы, 59 нчы «Адымнар-Чаллы» гимназияләре укучылары да тоттылар.

Язучылар Лилия Гыйбадуллина, Айдар Нуриев, Гөлназ Нуриева һәм Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназия укучысы Кәрим Нәсифуллин юбилярның шигырьләрен укыдылар. Кичәнең сценарий авторы – Валентина Ибраһимова, сәхнәгә куючы режиссер – Чаллы татар дәүләт драма театры артисты Зөлфия Галиуллина иде.

Кичәдә Үзәк китапханә тарафыннан Чаллы язучылары иҗатына һәм Данис Хәйруллинга багышланган бай күргәзмә оештырылган иде.

Бәйрәм барышында язучылар Лира Ибраһимовага Татарстан мәдәният министрлыгының Рәхмәт хаты, Марс Яһудинга шәһәр Хакименең һәм Татарстан Язучылар берлегенең Рәхмәт хатлары; Данис Хәйруллинга Татарстан Язучылар берлегенең «Әдәбияттагы казанышлары өчен» медале; шулай ук Данис Хәйруллинга, Айгөл Әхмәтгалиевага, Әлфия Ситдыйковага, Сирень Якуповага Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» медале; Айдар Нуриевка, Лилия Гыйбадуллинага, Гөлназ Нуриевага, ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге хезмәткәре Валентина Ибраһимовага Конгрессның Рәхмәт хатлары; Айрат Шәйхетдиновка, Фәрит Имамовка Татарстан Язучылар берлегенең Рәхмәт хатлары тапшырылды.

**Лилия СИРАЕВА.**